Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**11 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның «11 » ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2022 елның «11 » ноябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2022 елның «11 » ноябрендә 17 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пункты террито-риясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакы-тлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен фай-даланугa ризамы":

1. Ягулык-майлау материаллары, МТЗ-82.1 тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен запас частьләр сатып алу.

2. Кырынды авылында су белән тәэмин итү өчен тирән насослар һәм материаллар сатып алу, ремонт һәм башка хезмәтләр.

3.Кырынды авылында урам утлары алу һәм урнаштыру, электрикка килешү буенча түләү һәм башка агымдагы чыгымнар.

4. Кырынды авылында куркыныч тудыручы коры агачларны кисү.

5. Крында авылындагы чишмәне төзекләндерү, материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 376 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 190 кеше, бу – 51,2% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 190 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында

гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Кырындыторак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Ягулык-майлау материаллары, МТЗ-82.1 тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен запас частьләр сатып алу.

2. Кырынды авылында су белән тәэмин итү өчен тирән насослар һәм материаллар сатып алу, ремонт һәм башка хезмәтләр.

3.Кырынды авылында урам утлары алу һәм урнаштыру, электрикка килешү буенча түләү һәм башка агымдагы чыгымнар.

4. Кырынды авылында куркыныч тудыручы коры агачларны кисү.

5. Крында авылындагы чишмәне төзекләндерү, материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен түләү

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Авыл җирлеге башлыгы — А. А. Нәфыйков